ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28 август 2024 ел № 5579

Башкарма комитетның «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасын раслау турында» 2022 елның 25 октябрендәге 5772 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Шәһәр Уставы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы Карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасын раслау турында» 2022 елның 25 октябрендәге 5772 номерлы Карарына (Башкарма комитетның 2023 елның 31 мартындагы 2593 номерлы, 2023 елның 22 декабрендәге 12417 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасын тормышка ашыру буенча чараларны финанслауны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Юл хуҗалыгы (юл фондлары)» 0409 бүлекләре (бүлекчәләре) буенча каралган акчалар хисабына 1 654 365,16 мең сум күләмендә тәэмин итәргә: 2023 ел – 597 662,59 мең сум, 2024 ел – 538 292,57 мең сум, 2025 ел – 518 410,00 мең сум.»;

2) кушымтада:

- 1 бүлектә «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» юлында «2024» графасында «518 410,00» цифрын «538 292,57» цифрына алмаштырырга;

- 3 бүлектә «УЮЧның норматив техник халәтен ирешелгән дәрәҗәләрдә саклап тоту» юлында «Финанслау һәм финанслау чыганаклары 2024» баганасында «518 410,00» цифрын «538 292,57» цифрына алмаштырырга;

4) 4 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программа чараларын тормышка ашыру өчен 1 654 365,16 мең сум күләмендә муниципаль бюджет акчаларын файдалану күздә тотыла: 2023 ел – 597 662,59 мең сум, 2024 ел – 538 292,57 мең сум, 2025 ел – 518 410,00 мең сум.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ф. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов